**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**02.06.2023 ел** **№ 716**

## Биектау муниципаль районы территориясендә бәйрәм һәм башка мәдәни-массакүләм чаралар уздырганда сәүдә оештыру турында

Биектау муниципаль районы территориясендә бәйрәм чараларын оештырганда һәм уздырганда ваклап сату челтәренең стационар булмаган объектлары эшчәнлеген тәртипкә салу, халыкка сәүдә хезмәте күрсәтү оештыруны һәм аның сыйфатын яхшырту өчен шартлар тудыру максатларында, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Биектау муниципаль районы башкарма комитеты турында нигезләмә хакында» 2005 елның 29 декабрендәге 30 номерлы карары нигезендә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы территориясендә бәйрәм һәм башка мәдәни-массакүләм чаралар уздырганда сәүдә оештыру турында нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм Биектау муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Р. Булгаковка йөкләргә.

Житәкче Д.Ф. Шәйдуллин

1 нче кушымта

Биектау муниципаль районы башкарма
комитетының 2023 елның 02 июне
№716 карары белән расланды

**Биектау муниципаль районы территориясендә бәйрәм һәм башка мәдәни-массакүләм чаралар уздырганда сәүдә оештыру турында нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Биектау муниципаль районы территориясендә бәйрәм һәм башка мәдәни-массакүләм чаралар уздырганда сәүдә оештыру турындагы әлеге Нигезләмә (алга таба - Нигезләмә):

- Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты оештырган бәйрәм чараларын үткәргәндә стационар булмаган сәүдә башкарганда, җирле үзидарә органнары һәм хуҗалык итүче субъектлар (юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар һәм физик затлар) арасында барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне, күңел ачу аттракционнары эшчәнлеген, һәм халыкка җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтүне җайга сала;

-сәүдә, җәмәгать туклануы, аттракционнарның стационар булмаган объектларын урнаштыру тәртибен, шулай ук хуҗалык субъектларына карата, алар тарафыннан бәйрәм сәүдәсен гамәлгә ашырганда куела торган таләпләрне регламентлаштыра.

1.2. Бәйрәм сәүдәсе дигәндә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан оештырыла торган бәйрәм чараларын уздырганда, товарларны стационар булмаган сәүдә объектлары аша сатуны һәм халыкка җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәтүне күздә тоткан хуҗалык субъектлары тарафыннан бер тапкыр (бер көн эчендә) сәүдә эшчәнлеген оештыру (алга таба - бәйрәм сәүдәсе) аңлашыла.

1.3. Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты һәм хуҗалык субъектлары арасында бәйрәм сәүдәсен оештыру буенча мөнәсәбәтләр Татарстан Республикасының гамәлдәге законнары һәм әлеге Нигезләмә белән җайга салына.

1.4. Хуҗалык итүче субъектларның бәйрәм сәүдәсендә катнашуы сәүдә хокукына рөхсәт нигезендә гамәлгә ашырыла (Нигезләмәгә 1 нче кушымта). Күрсәтелгән рөхсәт хуҗалык субъектлары тарафыннан бирелә торган Биектау муниципаль районы территориясендә бәйрәм сәүдәсе объектын урнаштыру хокукына гариза нигезендә рәсмиләштерелә (Нигезләмәгә 2 нче кушымта)

2. Бәйрәм сәүдәсен оештыру тәртибе

2.1. Бәйрәм сәүдәсе әлеге Нигезләмә, шулай ук Биектау муниципаль районы сайтында бәйрәм сәүдәсен оештыру турында басылып чыккан хәбәр нигезендә оештырыла, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

- уздыру датасы;

-уздыру урыны;

- ассортимент исемлеге һәм товар төркемнәренең процент нисбәте;

- бәйрәм сәүдәсен оештыручы;

- заявкалар бирү формасы һәм вакыты.

2.2. Бәйрәм сәүдәсен оештыру турындагы хәбәр үз эченә бәйрәм сәүдәсен оештыруның һәм анда бәйрәм сәүдәсен уздырганда хуҗалык итүче субъектлар катнашуының барлык җитди шартларын алырга тиеш.

2.3. Бәйрәм сәүдәсен оештыручы чара башланырга биш календарь көннән дә соңга калмыйча Биектау муниципаль районы рәсми сайтында бәйрәм сәүдәсендә катнашучылар турында игълан урнаштыра.

2.4. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге Биектау муниципаль районы территориясендә бәйрәм сәүдәсе объектын урнаштыру хокукына гаризаларны шәхсән, бәйрәм сәүдәсен оештыру турында хәбәрдә күрсәтелгән срокларда кабул итә. Заявкалар эш көннәрендә һәм эш вакытында 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр Биектау т/юл ст. пос., Кооператив ур., 5 й. адресы буенча кабул ителә.

2.5. Бәйрәм сәүдәсен оештыручы бәйрәм сәүдәсен уздыру башланганчы җиде көннән дә соңга калмыйча хуҗалык итүче субъектны урнаштыру схемасын раслый.

2.6. Бәйрәм чарасын үткәрү көнендә Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге хезмәткәрләре бәйрәм сәүдәсе объектларын, аттракционнарны һәм җәмәгать тукלануы предприятиеләрен урнаштыруны теркәү журналы нигезендә гамәлгә ашыралар.

3. Бәйрәм сәүдәсен гамәлгә ашыручы хуҗалык субъектларына таләпләр

3.1. Биектау муниципаль районы территориясендә бәйрәм сәүдәсе объектларын урнаштыру, әлеге Нигезләмә таләпләрен үтәү шарты белән, Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге (алга таба - оештыручы) белән алдан килештереп, бәйрәм чарасын үткәрү көнендә башкарыла.

3.2. Чарага узу өчен хуҗалык итүче субъектка түбәндәгеләр таләп ителә:

1) Биектау муниципаль районы территориясендә бәйрәм сәүдәсе объектын урнаштыру хокукына Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлегенә бәйрәм сәүдәсе үткәрелә башлаганчы кимендә 14 көн кала гариза (2 нче кушымта нигезендә) җибәрергә;

2) сәүдә хокукына рөхсәт алырга (әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендә).

3.3. Бәйрәм сәүдәсен гамәлгә ашыручы хуҗалык субъекты бурычлы:

- әлеге Нигезләмәнең 3 бүлегендә каралган бәйрәм сәүдәсендә катнашучыларга карата куела торган таләпләрне үтәргә;

- бәйрәм сәүдәсе өчен расланган товарларның ассортимент исемлеген гаризада күрсәтелгән исемлек нигезендә үтәргә.

- төгәл рәсмиләштерелгән бәя күрсәткечләр булуын һәм сатыла торган товар турында консультация бирүне тәэмин итәргә;

- бәйрәм сәүдәсе өчен җыела-сүтелә торган палаткалар, стеллажлар, җиңел җиһазлар (өстәлләр, урындыклар), товарлар һәм сатып алучы белән исәп-хисап ясау өчен өстәлләр кулланырга;

- күчмә сәүдә өчен кирәкле сәүдә инвентарьлары, товарлар урнаштыру өчен лотоклар, бер тапкыр кулланыла торган савыт-сабалар, төргәкләү материаллары,

салфеткалар, эскәтерләр, чүп-чар җыю өчен савытлар, башка матди-техник җиһазлау әйберләре белән җитәрлек күләмдә тәэмин итәргә;

- хезмәт күрсәтүче персоналны униформа, баш киемнәре белән тәэмин итәргә.

- контрольдә тоту органнарының керү мөмкинлеген тәэмин итәргә;

- пыяла савытта эчемлекләрне сатуга юл куймаска;

- сәүдә төгәлләнгәннән һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәннән соң, күчмә сәүдә алып бару урынын чүп-чардан җыештырырга;

- халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү, әйләнә-тирә мохитне саклау, янгын куркынычсызлыгы, ветеринария өлкәсендәге таләпләрне, аерым төр товарларны сатуга куела торган таләпләрне һәм гамәлдәге законнарда каралган башка таләпләрне үтәргә;

- сатып алучыларга дөрес сайлау мөмкинлеген тәэмин итә торган товарлар турында кирәкле һәм дөрес мәгълүматны үз вакытында күрсәтмәле һәм аңлаешлы формада җиткерергә;

-Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракларда товарларның гамәлдәге законнарда билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган документлар (туры килү турында сертификат яисә декларация, яки аларның билгеләнгән тәртиптә таныкланган күчермәләре), товар-озата баручы документлары, ветеринария озата баручы документлары булырга тиеш;

- азык-төлек продуктларын саткан очракта, эш урынында медицина тикшерүләренең тулы мәгълүматлары белән сатучының билгеләнгән үрнәктәге шәхси медицина кенәгәсе булырга тиеш;

- кабартылган батутлар, уен аттракционнары, спорт аттракционнары урнаштырылган очракта, гамәлдәге законнар таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән аттракционның, батутның яисә башка күңел ачу җиһазларының завод-җитештерүче техник паспортын яисә башка документын (рус телендә) үзең белән алырга кирәк.

Хуҗалык итүче субъект килүчеләр өчен мәгълүматны урнаштырырга һәм урам аттракционына сертификатта күрсәтелгән эксплуатация кагыйдәләрен үтәргә тиеш. Кешеләрнең тормышы һәм сәламәтлеге өчен куркыныч барлыкка килгәндә аттракционны эксплуатацияләү туктатылырга тиеш. Кеше гомеренә зыян китергән өчен җаваплылык бәйрәм чарасында аттракционны урнаштырган хуҗалык итүче субъектка йөкләнә.

-ветеринария законнары таләпләре нигезендә (мөрәҗәгать итүченең эшчәнлеге хайваннар һәм кошларны күрсәтү белән бәйле булса) үзең белән мәҗбүри вакцинацияләр, ветеринария эшкәртүләре, диагностика тикшеренүләре уздыруны раслый торган документлар булырга тиеш;

- үзең белән продукциягә документлар алырга һәм аларны контрольдә тотучы органнарның беренче таләбе буенча күрсәтергә;

- шәхси гигиена кагыйдәләрен үтәргә;

- бирелгән урын чикләрендә эшчәнлек алып барырга, җиһазларны билгеләнгән урын чикләрендә генә урнаштырырга, сумкалар, төргәкләр, тартмалар, арбаларны һ.б. күренеп торган җирләрдән алырга, товарларны тезү өчен баулар һәм кыстыргычлар кулланмаска;

- эш тәмамланганнан соң, эшчәнлек алып барганда кулланылган палаткаларны, сәүдә җиһазларын, буш тараны һәм башка предметларны җыештырырга;

- урында чисталык һәм тәртип сакларга, чүпне махсус билгеләнгән

контейнерларга гына ыргытырга;

- асфальт өслеккә зыян китермәскә, җиһазлар урнаштыру өчен металл штырьлар, казыклар һәм башка предметлар кулланмаска, алар асфальт өслеккә зыян китерә;

-Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарын, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларын, әлеге Нигезләмәнең таләпләрен һәм Биектау муниципаль районының башка муниципаль хокукый актларын үтәргә;

-товарлар сату үлчәү чараларын (үлчәү, гер, үлчәү савытлары, метр һәм башкаларны) кулланып башкарылган очракта, сәүдә урынында сатучылар тарафыннан метрологик кагыйдәләргә һәм нормаларга туры килә торган үлчәү приборлары урнаштырылырга тиеш.

Үлчәү приборлары товарларны үлчәү, аларның бәясен билгеләү, шулай ук аларны җибәрү процессларын ачык һәм аңлаешлы формада тәэмин итәрлек итеп урнаштырылырга тиеш;

- җәмәгать туклануы хезмәтләрен гамәлгә ашыру өчен сәүдә урыннары мәҗбүри тәртиптә килүчеләргә кимендә 8 утыру урыны һәм бер тапкыр кулланыла торган савыт-сабаны җыю савытлары белән җиһазландырылырга тиеш;

- Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракларда Россия Федерациясе территориясендә чит ил гражданы тарафыннан хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыруга рөхсәткә ия булырга;

- вәкаләтле вәкилләр таләбе буенча түбәндәге документлар булырга һәм күрсәтелергә тиеш:

а) Бердәм дәүләт юридик затлар реестрына кертү турында таныклык оригиналы яисә нотариаль таныкланган күчермәсе (төп нөсхәсен биргән салым органы таныклаган) (таләп юридик затларга кагыла);

б) Бердәм дәүләт индивидуаль эшкуарлар реестрына кертү турында таныклык оригиналы яисә нотариаль таныкланган күчермәсе (төп нөсхәсен биргән салым органы таныклаган) (таләп индивидуаль эшкуарларга кагыла);

в) Россия Федерациясе гражданы паспорты (таләп хуҗалык итүче субъект хезмәткәрләренә кагыла);

г) Сәүдә урынында эшне башкаручы сатучы белән хезмәт шартнамәсенең төп нөсхәсе (эш бирүче тарафыннан таныкланган күчермә) (таләп ялланып эшләүчеләрне җәлеп итеп, бәйрәм сәүдәсендә товарлар сату эшчәнлеген гамәлгә ашыручы юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга кагыла).

## 4. Оештыручыга таләпләр

4.1. Оештыручы Биектау муниципаль районы территориясен җыештыру эшчәнлеген гамәлгә ашыра, массакүләм чаралар уздыру урыннарын чүп җыю контейнерлары, әлеге территорияне җыештыру белгечләре, бәйрәм чаралары көне дәвамында әлеге территорияне җыештыру һәм чүп-чарны (кар) чыгаруны тәэмин итә.

4.2. Оештыручы, техник мөмкинлек булганда, массакүләм чаралар үткәрелгән көнне сәүдә нокталарын электр энергиясенә тоташтыруны тәэмин итәргә мөмкин.

## 5. Хуҗалык итүче субъектларның хокуклары

5.1. Товарлар сату, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтү һәм аттракционнарның гамәлдә булуы эшчәнлеген гамәлгә ашырганда хуҗалык итүче

субъект хокуклы:

- Оештыручы биргән урында эшчәнлек алып барырга;

- эшне оештыру мәсьәләләрен хәл итү өчен Оештыручыга мөрәҗәгать итәргә.

5.2. Хуҗалык итүче субъектлар сәүдә хокукына рөхсәт нигезендә бәйрәм сәүдәсен гамәлгә ашырырга хокуклы.

## 6. Бәйрәм сәүдәсендә катнашу шартлары

6.1. Оештыручы хокуклы:

- бәйрәм сәүдәсен гамәлгә ашыру өчен гомуми файдаланудагы җирләрдә конкрет урынны (урыннарны) билгеләргә;

- бәйрәм чараларын үткәрүдә катнашучы хуҗалык субъектлары өчен бәйрәм сәүдәсен оештыруга карата таләпләрнең үтәлешен тикшереп торырга;

- хуҗалык итүче субъектка сәүдә хокукына рөхсәт бирүдән баш тартырга, әгәр:

а) эшкуарлык эшчәнлеге дәүләт теркәвеннән башка гамәлгә ашырылса, шулай ук эшчәнлек салым органында исәпкә куелмыйча алып барылса,

б) юридик зат, индивидуаль эшкуар, һөнәри керемгә салым түләүче физик зат эшчәнлеге төре бәйрәм сәүдәсендә объектны урнаштыруның күздә тотыла торган урыны билгеләнүгә туры килми,

г) элегрәк мондый чаралар уздырганда хуҗалык итүче субъект гамәлдәге нигезләмәне бозуга юл куйган булган,

д) продукция ассортименты санитар-эпидемиологик күзәтчелекне гамәлгә ашыручы орган тарафыннан сатучыларга карата куелган таләпләргә туры килмәгән очракта, һәм мондый орган тарафыннан мондый туры килмәү турында Оештыручы адресына җибәрелгән язмача белдерү булган очракта.

6.2. Оештыручы бурычлы:

-Биектау муниципаль районының рәсми сайтында бәйрәм сәүдәсен оештыру турында игълан бастырып чыгарырга;

- хуҗалык итүче субъектка гариза бирү чираты нигезендә сәүдә эшчәнлеген гамәлгә ашыруга, соңгысының бәйрәм сәүдәсендә катнашу шартларына туры килгәндә, урын бирергә;

- эшне Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының әлеге Нигезләмәсе нигезендә оештырырга;

- хуҗалык итүче субъектларның мөрәҗәгатьләрен оператив карарга, бәйрәм сәүдәсен оештыручы компетенциясенә кагылышлы мөрәҗәгатьләрнең асылы буенча чаралар күрергә.

## 7. Әлеге Нигезләмәне бозган өчен җаваплылык

7.1. Санитария кагыйдәләрен, төзекләндерү өлкәсендәге кагыйдәләрне, объектларны эксплуатацияләгәндә куркынычсызлык таләпләрен бозган, шулай ук Нигезләмәдә күрсәтелгән объектларны урнаштыру шартларын үтәмәгән юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар һәм һөнәри керемгә салым түләүче физик затлар Татарстан Республикасы законнары нигезендә җаваплы булалар.

7.2. Юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар һәм һөнәри керемгә салым түләүче физик затлар гомуми файдаланудагы шәһәр территорияләрендә тышкы төзекләндерү объектларына зыян китергәндә, китерелгән зыянны тулы күләмдә капларга тиеш.

7.3. Әлеге Нигезләмәнең үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль

районы Башкарма комитетының тиешле вәкаләтле органнары гамәлгә ашыра.

7.4. Бәйрәм сәүдәсен оештырганда хокук бозулар ачыкланган очракта, хуҗалык итүче субъект административ хокук бозулар турындагы законнарда каралган тәртиптә административ җаваплы була.

1 нче кушымта

Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2023 елның 02 июне №716 карары белән расланды

Биектау муниципаль районы башкарма комитеты
№__________ бәйрәм сәүдәсенә хокук
________________________________(дата) бәйрәм көненә

Түбәндәге хуҗалык итүче субъектка бирелде:
____________________________________________________________________
(оешма, индивидуаль эшкуар яисә һөнәри керемгә салым түләүче физик зат исеме)
Юридик адресы: _________________________________________________
Сәүдә эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен
Специальләшүе: ____________________________________________________
Эш режимы: _____________________________________________________
Сәүдә шартлары:
- тиешле тышкы күренеше булу;
- прайс бите/бәя күрсәткечләре булу;
- чүп савытлары булу һәм сәүдә тәмамланганнан соң сәүдә урынын җыештыру.
Рөхсәт Хуҗа тарафыннан түбәндәгеләр үтәлгән очракта бирелә:
сәүдә кагыйдәләре, санитария нормалары һәм кагыйдәләре, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре, ассортимент исемлеге.
Хуҗа сатыла торган продукциянең сыйфаты өчен гамәлдәге законнар нигезендә җаваплы була.
Гамәлдә булу срогы __________________________

2 нче кушымта

Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2023 елның 02 июне № 716 карары белән расланды

Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесе урынбасары
_________________________________________
кемнән_________________________________
_ (хуҗалык итүче субъект) _____________
Җитәкченең ФИА тулысынча:
________________________________________
Теркәлү адресы ____________________
_________________________________________
Телефон: _______________________________

**Хөрмәтле_______________________!**

Сездән миңа _______________________________________________________________________________ чарасында күчмә сәүдә белән катнашырга рөхсәт итүегезне сорыйм.
Сатыла торган товар ассортименты:
_______________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________

Сәүдә объектының төре (палатка, өстәлләр, зонт астындагы өстәл)
_______________________________________________________________________________
**кирәклесен ассызыкларга күләмнәрен күрсәтергә**

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгымны бирәм.

Җәмәгать туклануы күчмә сәүдәсен оештыру кагыйдәләре, Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсенең Арча, Биектау районнарында территориаль бүлеге таләпләре һәм янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре белән таныштырылдым, үтәргә сүз бирәм.

Үземә сатыла торган товарларның сыйфаты һәм куркынычсызлык чараларын үтәү өчен җаваплылык алам. Чисталык һәм тәртипне гарантиялим.

Дата________________ имза____________________